# САЛИХ СӘЙДӘШЕВ



***Балалар өчен җырлар***

Рәсемнәрдә Салих

Сәйдәшев җырлары

сурәтләнгән.

Сез аларның исемнәрен

дөрес итеп әйтеп бирегез.

Белсәгез, җырны җырлагыз.



Бу җыр
нәрсә
турында?
Җырның
исемен
әйтегез.



1 БИРЕМ

# З Ә Ң Г Ә Р   К Ү Л

Г. Насретдинов сүзләре

Зәңгәр күл-бик матур күл,
Тирәсе  камышлык.
Аның белән без  әле
Тик быел  таныштык.
    Күлнең  зәңгәр  суларын
    Чәчрәтеп уйныйбыз.
    Шундый  рәхәт, күңелле!-
    Уйнап  һич  туймыйбыз.
Йөзәбез колач салып,
Баш  белән  чумыбыз.
Елмая  күктә  кояш,
Без ярга  чыгабыз.
    Безнең  лагерьурманда,
    Зәңгәр  күл янында.
    Киләсе  елга  бире
    Килербез  тагын  да.

**2 БИРЕМ** Рәсемнәргә карап җырның исемен әйт.









# К И Л Д Е  Я З

Әхмәт Ерикәй сүзләре.

Киң итеп җәеп колач,
Килде яз, килде яз.
Елмаеп көлә кояш,
Көн аяз, көн аяз,

Кыш буе яуган карлар,
Эределәр, эределәр,
Сыерчыклар, тургайлар
Килделәр, килделәр.

Ап-ак чәчәк аттылар
Шомыртлар, шомыртлар.
Тау артына актылар
Болытлар, болытлар.

Син, кояш, җиребезгә
Сип нурлар, сип нурлар.
Мул уңыш бирсен безгә
Киң кырлар, киң кырлар.

3 БИРЕМ







# ЯШЬ ТУРИСТЛАР ҖЫРЫ

Шәйхи Маннур сүзләре

Юлга чыктык без бергә
Туган илдә йөрергә.
Туган илнең төрле җирен,
Байлыкларын күрергә.
Мендек биек тауларга,
Йөрдек киң яланнарда.
Учак ягып, үлән түшәп
Кундык без урманнарда.
Без җырлашып үткәндә,
Юлдаш булды шаян җил.
Кай якларда йөресәң дә,
Матур икән Туган ил!





4 БИРЕМ

# ЧИЯЛӘР ЧӘЧӘК АТСЫН

Әхмәт Ерикәй сүзләре

Матурланып таңнар атсын,
Йомшак җилләр иссеннәр,
Алмагачлар зур үссеннәр,
Чияләр чәчәк атсын!..

Тургай кырны яңгыратсын,
Шат яшәсен дус-ишләр.
Җиргә таратып хуш исләр,
Чияләр чәчәк атсын.

Чишмәләр чылтырап аксын
Шаярып уйнап-көлеп.
Туган илне ямьгә күмеп,
Чияләр чәчәк атсын!..





5 БИРЕМ

